# СУГЫШ КАЙТАВАЗЫ

Азнакай районы Чубар-Абдул урта мәктәбенең I категорияле укытучысы Йосыпова Энҗе

ИСӘНЛӘШТЕК,ХӘЛ БЕЛЕШТЕК

ЕЛМАЕШЫП КӨЛЕШТЕК.

ЯХШЫ КӘЕФ БЕЛӘН ХӘЗЕР

БЕЗ ДӘРЕСКӘ КЕРЕШТЕК.

# КАЙТАВАЗ ТУРЫНДА НИЛӘР БЕЛӘБЕЗ?

Кайтаваз- эхо, отклик.

# Бөек Ватан сугышы

*1941-1945*




- Бик күп кан, күз яше түгелгән, озакка сузылган дүрт ел. Ул еллар әле бүген дә һич узып китмәслек озын булып тоела. Ә сугыш барганда, һәр йортны, һәр гаиләне кайгы, үлем сагалап йөргән. Соңгы өметне өзеп, өйләргә үлем язулары килгән.

# “Барасы да фронт өчен, барасы да җиңү өчен!”

Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен!” – бу лозунг аның коралына әйләнде. Җинүгә, фронт белән беррәттән, завод – фабрика цехларында зур өлеш кертелде. Татарстанга илнең башка төбәкләреннән җитмештән артык завод һәм фабрика күчерелде. Аның күп предприятиеләре корал, сугыш кирәк – яраклары җитештерүгә үзгәртеп корылды. Республика сугышчыларга берөзлексез 600 дән артык төр корал, кием - салым, азык – төлек озатып торды.

# Фронтта югалганнар

- Әйе, фронтка ярдәм күп булды. Җиңу зур корбаннар таләп итте. Татарстанның 560 меңнән артык улы һәм кызы илне сакларга китте, аларның 250 меңнән артыгы кире әйләнеп кайта алмады, сугыш кырларында ятып калды. Дошманга каршы сугышларда күрсәткән батырлыклары өчен ике йөздән дә күбрәк якташыбызга иң югары мактаулы исем – Советлар Союзы Герое исеме бирелде,егерме тугыз сугышчы Дан орденының тулы кавалеры булды.
- Еллар уза, дөньяга яңа буыннар килә. Ватан сугышы беткәнгә дә инде 71ел вакыт узып бара. Әмма сугыш хатирәләре, дошманга күкрәк киереп каршы торган, изге җиребезне илбасарлардан саклап калган, аның иминлеге өчен гомерен дә кызганмаган каһарманнар һичкайчан онытылмас.

# Сугыш еллары









# СҮЗЛЕК ӨСТЕНДӘ ЭШ

ХАРАМ- ХӘРӘМ (КЕШЕ ӘЙБЕРСЕ)

ХУРЛАР-ХУРЫ- БИК МАТУР



# Заһирә Гомәрова “Батырлар хакында” 3 кисәк 100 бит

- Батырлар нинди газаплар күргән?
- Ни өчен аларны батыр дибез?
- -Шигырьнең соңгы куплетында автор кемгә мөрәҗәгать итә?

# Ренат Харис
# “Сугыш турында сөйләшә картлар”

- Ни өчен картлар сугыш турында пышылдап кына сөйләшә?
- Ничек уйлыйсын, бу сөйләшү шатлыклымы? Әллә сагышлымы?
- Ни өчен тирә-юнькарт солдатларга рәхмәт укый?
- Сугыш турында нинди кинолар караганыгыз бар? Алар кызыкмы, әллә кызганычмы?

# Рефлексия

-Бу дәреснең кайсы өлеше сезгә аеруча ошады? Ни өчен?

-Син дәрестә үзен әчен нинди яңалык ачтың?

-Сез бабайларны тыңларга яратасызмы?

--Кайсы урынар сиңа аңлашылып җитмәде?

-Бугенге дәрестә үз җавапларыңа нинди билге куяр идең?

# Өй эше

З.Гомәрованың “Батырлар хакында” шигырен ятларга. (100-101 нче бит, хрестоматия)